| Каралган | Килешенгән | Раслыйм |
| --- | --- | --- |
| МБ житәкчесе | «Яңа Мәлкән гомуми төп белем мәктәбе» ГБМУнең УТЭБДУ | «Яңа Мәлкән гомуми төп белем мәктәбе» ГББМУнең директоры |
| ______ /Калинина М.Б./ | ______ / Сәгъдиева Г.Ф./ | ______ Әхмәтшина Л.М./ |
| беркетмә № 1 | «20» август 2013 ел. | Приказ № 92 |
| «20» август 2013ел. | | «28» август 2013 ел. |

уку фәненнән

# ЭШ ПРОГРАММАСЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы

«Яңа Мәлкән ТГБМ» ГББМУ

Калинина Мәкфия Биктимер кызы, 1 категорияле укытучы

уку, 4 нче сыйныф

Педагогик совет
утырышында каралган.
беркетмә № 1
« 20 » август 2013 ел.

2013 – 2014 нче уку елы

## АҢЛАТМА ЯЗУЫ

Әдәби укудан (4 сыйныф) эш программасы түбәндәге документларга нигезләнеп төзелде:

-“Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында” Татарстан Республикасы Законы (2004 ел, 1июль);

-башлангыч гомуми белем бирү программалары (татар һәм рус телләре, 1-4 ) Казан, “Мәгариф” 2010.

- Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан расланган 2010 нчы елгы “Башлангыч гомуми белем бирү программалары”на нигезләнеп төзелде. Авторлары: С.Г.Вагыйзов, Р.Х.Ягъфәрова.
- Дәреслек: Уку китабы. М.Х.Хәсәнова, Р.М.Миңнуллин, И.Х.Мияссарова. Казан. “Мәгариф”. 2010 нчы ел.

Программа 70 сәгатькә исәпләнелгән, атнага 2 сәгать.

*Уку дәресләренең төп бурычы – укучыларда йөгерек, аңлы, сәнгатьле уку күнекмәләре булдыру, текст һәм китап белән эшләү осталыгы тәрбияләү*.

**Уку күнекмәләре.** Дөрес , аңлап, тиешле дәрәҗәдә йөгерек һәм сәнгатьле уку. Интонацияне текст эчтәлегенә бәйле рәвештә сайлау. Уку тизлеген сүзне тулы һәм төгәл күрергә, тиз аңларга өйрәтү исәбенә үстерү. Эчтән уку алымына зур күләмле һәм күптөрле текстларны укытып өйрәтү. Сәнгатьле уку осталыгын камилләштерү. Авазларны ачык һәм дөрес әйтүгә ирешү.Укыганда орфоэпия нормаларын үтәү, уку тизлеген эчтәлеккә бәйле рәвештә сайлау, аны арттыра һәм киметә белү, сөйләм максатына карап , тавышны көчәйтеп яки пышылдап уку. Әдәби әсәрләрне рольләргә бүлеп укырга һәм сәхнәләштерергә өйрәтү. Сәнгатьле укуга хәзерләнә белү: эчтәлекне аңлау, сурәтләнгән күренешне ачык итеп күз алдына китерү, фраза һәм шигырь юлларының яңгырашын ишетү, ритмын отып алу, башкару максатын аңлау.

**Текст өстендә эшләү**. Әсәрне тыңлаганда һәм укыганда төп фикерне тотып ала белү, хикәяләүнең логикасын , тексттагы мәгънәви һәм интонацион бәйләнешләрне аңлау.. Вакыйгаларның эзлеклелеген , үзара бәйләнешен билгеләү. Сүзле картина элементлары кертеп , укылган текстның эчтәлеген тулысынча, сайлап , кыскача сөйләү, җавапның дөреслеген тексттан өзекләр укып раслау. Текстны мөстәкыйль рәвештә мәгънәле кисәкләргә бүлүйәм аларда чагылдырылган төп фикерне таба белү. Укытучы ярдәмендә план төзү. Кешеләрне , табигатьне , күренешләрне сурәтләү өчен автор кулланган сүзләрне табу.. Әсәр геройларының эш – кыланышларына , уй- хисләренә һәм алар нигезендә яткан сәбәпләргә укытучы ярдәмендә бәя бирү. Әдәби әсәрнең тел чараларына игътибарлы булу, андагы сурәтләү чараларын аңлау. Шигъри сүзгә игътибарлы булу, тексттан эпитет , чагыштыру , метафораларны табу, чагыштыруга вариантлар сайлау.

Балалар белергә тиешле әдәби жанрлар: әкият һәм хикәя, шигырь һәм мәсәл, халык авыз иҗаты әсәрләре( табышмак, мәкаль, әйтем, җыр, бәет ).

Уку һәм балалар китабы белән эшләү. Дәреслекнең эчтәлек өлешеннән әсәрләрне исеме буенча табу, бер темага караган әсәрләрне аеру. Китап авторы белән танышу, аның исем- фамилиясен , китаптагы портретын табу, берничә китабын чагыштырып , иҗатының темасын билгеләү. Укылган әсәр буенча әңгәмәдә катнашу, сорауны ишетү, аңлау, темага бәйле рәвештә җавап бирү, үз фикереңне дәлилләү өчен әсәрдән өзекләр китерә белү.Укылган китап турында , темасын , геройларын , вакыйгаларын чагылдырып һәм үз мөнәсәбәтеңне белдереп , 4-5 җөмләдән торган хикәя язу.

**Бурычлар**:

- баланы матур әдәбият әсәрләре дөньясына алып керү һәм сүз сәнгатенең образлылыгын аңларга өйрәтү;
- төрле жанрдагы әдәби әсәрләр белән таныштыру;
- яңа китаплар белән танышуга, элеккеләрен кабат укуга теләк тәрбияләү, китап укудан ләззәт, хозурлык табарга өйрәтү;
- әсәрне уку – аның “серенә” төшенү икәнлеген аңлату, авторның позициясен, язылганга мөнәсәбәтен ачарга өйрәтү, автор белән аралашу өчен уку;
- әсәрдәге сүзне укучының игъә кую; аны образлар тудыру алымы, авторның фикерен, уйларын, хисләрен белдерүче чара, автор ачкан могҗиза буларак кабул итәргә өйрәтү;

- укучыларның әсәрне эмоциональ- эстетик кабул итүенә ирешү, хисләр сферасын әхлакый, рухи матурлык тойгылары белән баету;
- әдәби әсәрне укыганда, балаларның акылын, ихтыярын, хисләрен һәм рухи ихтыяҗларын үстерү.

Башлангыч сыйныфларда уку һәм югары сыйныфларда әдәбият дәресләре нигездә охшаш, ләкин һәркайсында әдәби әсәр белән таныштыру балаларның яшь үзенчәлекләренә карап оештырылырга тиеш. Түбән сыйныфларда уку дәресе әдәбият дәресе түгел, уку дәресе булып кала – беренче урында **уку техникасын үстерү бурычы** куела.

Программаны нәтиҗәле үтәү дә балаларның тормыш тәҗрибәсе туплавына бәйле. Дәреслекләрдә балалар күңел үсү һәм кәеф китү, ярсу һәм өметсезлек, канәгатьлек хисе һәм кызыклы фикер һки әсәр героеның эшләнгән эшеннән күңел булу тойгыларын кичерергә тиеш.

Дәрестән тыш уку программада аерым күрсәтелми. Мөстәкыйль уку өчен биремнәр дәреслекләрдә өйрәнелгән әсәргә бәйле рәвештә куелырга тиеш. Алар сыйныфта укылганны тулыландыра, укучыны үзе теләп китап укырга һәм төрле чыганаклардан мәгълүмат табарга өйрәтә.

Сүз сәнгате белән таныштыру максатыннан , 2 – 4 сыйныфларда әдәбият белеменнән мәгълүматлар бирелә: автор турында белешмә, әдәбиятнең төрле жанрлары һәм аларның үзенчәлекләре, әсәрнең темасы, төп фикере, фольклорның кече жанрлары үзенчәлекләре, чагыштыру , эпитет, метафора, җанландыру, рифма , строфа. Бу терминнарны үзләштерү әсәрне аңлау өчен кулланыла. Сәнгатьле уку – әсәрне ( геройларның халәтен , аларның кичерешләрен , авторның темага , эчтәлеккә мөнәсәбәтен , язылганның матурлыгын ) тирәнтен аңлау нәтиҗәсе.

**Тематик планлаштыруны тормышка ашырганда куелган иң әһәмиятле максатлар:**

1. Тиз, аңлап, дөрес итеп укырга өйрәтү;
2. Балаларны ашыкмыйча, сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтү;
3. Балаларның активлыгын үстерү;
4. Уй - фикерен ачык итеп әйтү өчен тема белән кызыксынырга, уку мәсьәләсен чишәргә өйрәтү;
5. Уйлау алымнарына өйрәтү һәм үз уен теләп әйтеп бирергә күнектерү

Моңа бәйле рәвештә II – IV сыйныфларда уку дәресләренә түбәндәге **бурычлар** куела:

- Баланы сүз сәнгатенең образлылыгын аңларга өйрәтү;
- Төрле жанрдагы әдәби әсәрләр белән таныштыру;
- Китап укудан ләззәт, хозурлык табарга өйрәтү;
- Әсәрне уку, аның серенә төшенү икәнлеген адлату, авторның язылганга мөнәсәбәтен ачарга өйрәтү;
- Укучыларның әсәрне эмоициональ – эстетик кабул итүенә ирешү;
- Әдәби әсәрне укыганда, балаларның акылын, ихтыярын, хисләрен һәм рухый ихтыяҗларын үстерү.

Дәреестән тыш уку программада аерым күрсәтелми. Мөстәкыйль уку өчен биремнәр дәреслекләрдә өйрәнелгән әсәсргә бәйле рәвештә куелырга тиеш. Алар сыйныфта укылганны тулыландыра, укучыны үзе тәләп китап укырга һәм төрле чыганаклардан мәгълүмат табарга өйрәтә.

**Кычкырып, аңлап, дәрес һәм сәнгатьле уку тизлеге (1 мин)**

| сыйныфлар | I нче ярты ел ахыры | Уку елы ахыры |
|---|---|---|
| I | - | 30 сүз |
| II | 40 сүз | 50 сүз |
| III | 60 сүз | 75 сүз |
| IV | 85 сүз | 95 сүз |

## ПРЕДМЕТНЫҢ ГОМУМИ БАШЛАНГЫЧ БЕЛЕМ БИРҮНЕҢ ДӘҮЛӘТ СТАНДАРТЫН ИСӘПКӘ АЛГАН ТЕМАТИКАСЫ ҺӘМ ЭЧТӘЛЕГЕ

| № | Эчтәлек | Сәг. |
|---|---|---|
| 1 | **Туган якта җәй һәм көз**<br>М.Гафури "Ана теле". И.Гази "Кояш артыннан киткән тургай". Р.Миңнуллин "Җәйнең яшел аты". Г.Исхакый "Идел буе көзләрендә". Ә.Бикчәнтәева "Көз". | 4 |
| 2 | **Татар халык авыз иҗаты**<br>Җырлар."Әлли-бәлли бәү"."Ананың сүзен ишет". Кыска җырлар. Мәкальләр һәм әйтемнәр. Табышмаклар. Әкиятләр. "Өч сорау", "Гакыл "Унөч", "Каракош", "Камыр батыр", "Наян төлке". | 8 |
| 3 | **Мәшһүр татар язучылары һәм шагыйрьләре**<br>Г.Тукай "Исемдә калганнар", "Китап", "Туган авыл", "Шүрәле", "Сөткә төшкән тычкан", "Арыслан илә тычкан", "Бәхет".<br>Ф.Әмирхан "Ай өстендә Зөһрә кыз". Кәрим Тинчурин "Очрашу". Ш.Камал "Курай тавышы". Г.Ибраһимов "Яз башы".<br>Һ.Такташ "Кыш җыры". Х.Туфан шигырьләре "Һәркемнең үз теле...", "Илгә сәлам", "Дөньяның мин күрдем суын...", "Иркәләнеп кояш нурында...", "Сез таныйсызмы?". Ш.Маннур "Әткәм-әнкәмнең теле". М.Җәлил "Кечкенә дуслар", "Бакчачы", "Яз", "Урман", "Бер үгет", "Карак песи". И.Гази "Сиртмәкойрык". Ф.Хөсни "Сөйләнмәгән хикәя". С.Хәким шигырьләре. "Ява яңгыр, ихласланып ява...", "Тукайга", "Җитлегеп килгән игеннәр...", "Туган якта һәртал җырлый". Г.Бәширов "Язгы Сабантуйлар". Ә.Еники "Матурлык". Н.Исәнбәт комедиясе. Аяз Гыйләҗев "Дүртәү". Мирсәй Әмир "Җиргән теле".<br>***Әдәбият белеменнән мәгълүматлар:*** Юмор, драма, комедия турында төшенчә бирү. | 20 |
| 4 | **Туган якта кыш һәм яз.**<br>Зыя Мансур шигырьләре. "Кырмыска", "Озын колак баласы елак-мылак", Н.Думави "Беренче кар". Г.Хәсәнов "Декабрь".<br>Г.Камал "Масра авылында яз башы". Г.Ибраһимов "Балыкка..." | 4 |
| 5 | **Тәрҗемә әсәрләр**<br>Якоб Гримм, Вильгельм Гримм "Кызыл калфак". Ханс Христиан Андерсен "Патшаның яңа киеме". А.С.Пушкин "Балыкчы һәм балык турында "Балачак". Максим Горький "Мин ничек укыдым". Марк Твен "Том Сойер маҗаралары". Антуан де Сент –Экзюпери "Нәни принц". | 7 |
| 6 | **Шигъририят дәфтәре**<br>Габдерәхим Утыз Имәни-әл Болгари "Заманга ияру турында".<br>Дәрдемәнд "Ачылды, кар эреп, таулар, тугайлар...","Түкте кояш нурларын тын-сары","Таулы матур илләрендә...". "Көлемсерәп көн башланды..." ил матур, бу ил күркәм"Нәҗип Думави "Җәйге айлы төн". Ф.Кәрим "Гармун турында".<br>Р.Әхмәтҗан "Тургай җыры". "Инде кич", "Тирәкләр җил көтә...", "Кайту шатлыгы", "Бер фәлсәфә". | 6 |

| | | |
|---|---|---|
| | ***Әдәбият белеменнән мәгълүматлар:*** Шигырь турында төшенчә бирү. Рифма, строфа турында төшенчә бирү. Эпитет, чагыштыру, метафора, с төшенчә бирү. | |
| **7** | **Язучылар-балаларга**<br>Каюм Насыйри “Әбүгалисина”. Абдулла Алиш “Сертотмас үрдәк”.<br>Р.Хафизова “Киек каз юлы”. Ш.Галиев “Иң беренче сүз”, “Карандаш төпчегенең ак кәгазь белән хушлашуы” ,“Сүзләр иленә сәяхәт”, “Ялкау д үзләре”, “Хәзинә”, “Без-Тукай оныклары”,<br>Р.Миңнуллин “Югалган көн”. “Саный беләм”. “Дөньядагы иң зур алма”.<br>Ләбибә Ихсанова “Җир астында җиде көн”, Нәби Дәүли “Каракай-йорт эте”,<br>Т.Миңнуллин “Кәрлә-мәктәп баласы”. Н.Фәттах “Энҗеле үрдәк”.<br>Г.Сабитов хикәяләре “Чүкеч”, “Тәүге соклану”, “Тәүге шатлык”, “Тәүге батырлык”. М.Юныс “Җиде могҗиза”, “Мисыр пирамидалары”.<br>Ә.Бикчәнтәева “Каз бәбкәләре”. “Җил сөйләшә беләме?”.<br>Ф.Яруллин “Туган ягы кирәк кешегә”, “Тугры дус”. “Рәхәт тә соң!” “Гайни”. | **19** |

**Татар халык авыз иҗаты.**

**Әкиятләр:** “Өчсорау”, “Гакыллы хәйлә әкияте”, “Унөч”, “Каракош”. Әдәбият белеменнән мәгълүматлар.

Нәфис сүзнең мөмкинлекләрен: тасвирлы, тәэсирле булуын һәм алмаштырып булмаганлыгын ачыклау өстендә эш.

**Мәшһүр татар язучылары**: 3 нче сыйныф өчен күрсәтелгән язучыларның яңа әсәрләре.

И.Гази, Г.Камал, А.Гыйләҗев, Т.Миңнуллин. Әдәбият белеменнән мәгълүматлар.

Әйткән уй-фикерне текстан өзек китереп раслау. Драма жанры.

**Шигърият дәфтәре**. 3 нче сыйныф өчен күрсәтелгән шагыйрьләрнең яңа әсәрләре. Н.Думави, М.Әгләмов, Зөлфәт, Р.Гатауллин.

Әдәбият белеменнән мәгълүматлар.Метафора. Дәлилләп шигырь сайлап ала белү. Бер темага язылган шигырьләрне берләштерү һәм чагыштыру.

**Язучылар – балаларга**. 3 нче сыйныфта күрсәтелгән авторларга Л.Ихсанова, Р.Хафизова, Г.Сабитов, Н.Фәттах, М.Юныс өстәлә.

Әдәбият белеменнән мәгълүматлар. Эпитет, метафора, чагыштыру турында белемнәрне тулыландыру. Текстан уй-фикерне дәлилләү өчен автор сүзләрен табу.

**Дөнья халыклары әдәбияте**. Төрле халыкларның татарчага тәрҗемә ителгән әкиятләре. А.Милн, А.Линдгрен, Д.Свифт, М.Твен.

Әдәбият белеменнән мәгълүматлар. Сатира белән танышу. Җанлы гәүдәләнешне чынбарлыкны тасвирлауда файдалану.

**Уку күнекмәләре.** Йөгереп, аңлап, дөрес, сәнгатьле уку һәм орфоэпия нормаларын үтәп тулы сүзләр белән уку. Уку тизлеге беренче ярты елда – 1 минутка 85 сүз, икенче ярты елда 95 сүз. Уку күнекмәләренең ике төрен дә (эчтән һәм кычкырып уку) интенсив үстерү. Төрле күләмдәге һәм жанрдагы әсәрләрне йөгерек һәм аңлап уку.

**Сәнгатьле уку** һәм сәнгатьле сөйләү күнекмәләрен камилләштерү. Интонация (тизлек, ритм, логик басым, сөйләм һәм укуның музыкаль яңгырашы) өстендә эш. Сәнгатьле укуга мөстәкыйль рәвештә әзерләү.

**Текст өстендә эш.** Укыганның төп фикерен мөстәкыйль әйтеп бирү, текстның мәгънәле кисәкләрен билгеләү. План яисә рәсем буенча текстның эчтәлеген тулысынча, сайлап яки кыскача сөйләү.Укытучы билгеләгән темага хикәя төзү өчен текстан материал сайлый белү.

Эчтәлекне төгәл һәм эзлекле сөйләү. Диалогларны хикәяләү формасына күчерә алу. Персонажларга характеристика бирү. Алар турында белешмәләрне берләштерү. Әсәр геройларының сөйләм үзенчәлекләрен билгеләү, үзеңнең һәм авторның геройга мөнәсәбәтен ачыклау.

**Дәреслек белән эшләү.** Эчтәлек өлешендә җиңел ориентлашу. Текстларга куелган сорау һәм биремнәрне мөстәкыйль үтәү, дәреслек нең методик һәм белешмә аппараты белән эш итү.”Абзац”, “кызыл юл”, “бүлек исеме” кебек төшенчәләрне аңлау һәм куллану.

**Балалар китабы белән эшләү.** Даими рәвештә китапка мөрәҗәгать итү, әдәби әсәрләрне укып бару ихтыяҗы тәрбияләү. Укыган һәм ишеткән турында фикер алышуга теләк уяту, китапны кабат укудан шатлык, канәгатьлек хисе кичерү өчен шартлар тудыру.

**Яттан өйрәнү** - дәрестә укылган яки программадан тыш сайланган 10-12 шигырь.

**Уку елы башына укучы балаларның әзерлеге дәрәҗәсе.**

**Укучы таныш булырга тиеш :**

- Әдәби әсәрләр, аларның авторлары
- Китапның элементлары (тышы, эчтәлеге, титул бите, иллюстациялар)

**белергә тиеш**:

- Аңлап эчтән уку
- Әсәрнең темасын һәм фикерен белү
- Эчтәлеген сөйләү
- Әсәрне өлешләргә бүлү, план төзү
- Вакыйгаларны бәяләү
- Сәнгатьле итеп яттан сөйләү
- Балалар әдәбиятының жанрлары (әкият, хикәя, мәсәл).

**Уку елы ахырына укучыларның белем һәм күнекмәләренә таләпләр:**

## УКУЧЫЛАРНЫҢ ӘЗЕРЛЕК ДӘРӘҖӘСЕНӘ ТАЛӘПЛӘР

| | |
|---|---|
| **1** | **Туган якта җәй һәм көз**<br>**Укучылар белергә тиеш:**<br>- өйрәнелгән әсәрнең исемен, төп эчтәлеген, авторын;<br>- әсәрнең геройларын, аларның эш-гамәлләрен, холык- фигылен, хис-кичерешләр дөньясын бәяли белү;<br>-дөрес, аңлап, тиешле дәрәҗәдә йөгерек һәм сәнгатьле, кычкырып һәм эчтән уку;<br>-интонацияне текст эчтәлегенә бәйле рәвештә сайлау.<br>**Укучылар эшли алырга тиеш:**<br>-башка кеше сөйләмен тыңлый белү;<br>- укылган текст буенча сорауларга дөрес җаваплар бирү;<br>- сүзләрне әдәби тел нормалары нигезендә дөрес әйтү;<br><br>-тексттан махсус тел-сурәтләү чараларын: чагыштыру, сынландыруларны табарга; |
| **2** | **Татар халык авыз иҗаты**<br>**Укучылар белергә тиеш:**<br>- әдәби жанрларны һәм халык авыз иҗатын аеру.<br>**Укучылар эшли алырга тиеш:**<br>-татар халык җырларын өйрәнү;<br>-мәкаль һәм әйтемнәрнең мәгънәсен аңлата белү;<br>-10 нан артык мәкаль һәм әйтемне яттан өйрәнү;<br>-әкиятләрне рольләргә бүлеп уку һәм сәхнәләштерергә өйрәнү ;<br>-укылган әкиятләрнең гади планын төзү;<br>-укылган әкиятләрнең эчтәлеген аңлау, тулысынча, сайлап һәм кыскача сөйли белү; |

| | |
|---|---|
| **3** | **Мәшһүр татар язучылары һәм шагыйрьләре**<br>**Укучылар белергә тиеш:**<br>- өйрәнелгән әсәрнең исемен, төп эчтәлеген, авторын;<br>- әсәрнең геройларын, аларның эш-гамәлләрен, холык- фигылен, хис-кичерешләр дөньясын бәяли белү;<br>- дөрес, аңлап, тиешле дәрәҗәдә йөгерек һәм сәнгатьле, кычкырып һәм эчтән уку;<br>- шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләү;<br>- өйрәнелгән әсәр авторының башка әсәрләре, иҗаты хакында белү.<br>**Укучылар эшли алырга тиеш:**<br>-укылган хикәянең гади планын төзү;<br>-укылган текстның эчтәлеген аңлау, тулысынча сайлап һәм кыскача сөйли белү;<br>-текстны темасын билгеләү, мәгънәле кисәкләргә бүлү, төп фикерне үз<br>сүзләрең белән әйтә белү;<br>-сурәтләү чараларын тексттан табу, аңлау; |
| **4** | **Туган якта кыш һәм яз**<br>**Укучылар белергә тиеш:**<br>- балалар өчен чыга торган газета – журналлар турында;<br>**Укучылар эшли алырга тиеш:**<br>-текстның темасын билгеләү, мәгънәле кисәкләргә бүлү, төп фикерне үз сүзләрең белән әйтә белү;<br>-сурәтләү чараларын тексттан табу, аңлау;<br>-бирелгән темага хикәя төзү, тиешле интонация белән сөйләү; |
| **5** | **Тәрҗемә әсәрләр**<br>**Укучылар белергә тиеш:**<br>- дөрес, аңлап, тиешле дәрәҗәдә йөгерек һәм сәнгатьле, кычкырып һәм эчтән уку;<br>- төрле мәгълүмат чыганаклары (сүзлекләр, белешмәләр, электрон чаралар) белән эшләү хакында.<br>**Укучылар эшли алырга тиеш:**<br>- әсәрнең сюжетын сөйләү;<br>- сурәтләү чараларын тексттан табу, аңлау;<br>- укылган текстның эчтәлеген аңлау, тулысынча, сайлап һәм кыскача сөйли белү;<br>-“абзац”, “кызыл юл”, “бүлек исеме” төшенчәләрен аңлый һәм куллана белү. |
| **6** | **Шигърият дәфтәре**<br>**Укучылар белергә тиеш:**<br>- дөрес, аңлап, тиешле дәрәҗәдә йөгерек һәм сәнгатьле, кычкырып һәм эчтән уку;<br>- шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләү;<br>- өйрәнелгән әсәр авторының башка әсәрләре, иҗаты хакында белү.<br>**Укучылар эшли алырга тиеш:**<br>- сурәтләү чараларын шигырьдән табу, аңлау;<br>-шигырьнең темасын билгеләү, мәгънәле кисәкләргә бүлү, төп фикерне үз сүзләрең белән әйтә белү;<br>- әдәби геройларга характеристика бирә белү;<br>-төрле шагыйрьләрнең бер темага язган шигырьләрен , аерым әдипнең төрле шигырьләрен чагыштыру;<br>-авторның геройга, вакыйгага , күренешләргә мөнәсәбәтен сиземли алу, үз фикереңне ачык әйтә белү; |

| | |
|---|---|
| | -шигырь язып карау; |
| **7** | **Язучылар-балаларга**<br>**Укучылар белергә тиеш:**<br>-2-3 зур күләмле әсәрнең(фольклор һәм мәшһүр язучыларның әсәрләре) исемен, темасын һәм сюжетларын.<br>**Укучылар эшли алырга тиеш:**<br>-хикәянең башламын, мөмкин булган дәвамын һәм ахырын уйлап чыгару.<br>- текстта автор һәм катнашучыларның сүзләрен, табигать күренешләрен аерып күрсәтү;<br>-әсәрнең төп геройларына бик гади характеристика бирү. |

-

**Укучыларның белеменә, эш осталыгына һәм күнекмәләренә куелган таләпләрне үтәүдә максатка ирешү өчен:**

- Яңа информацион технологиялар куллану;
- Эзләнү-проект эшчәнлеген кертү;
- Сәламәтлек саклау технологиясен куллану.

## ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


1.Башлангыч гомуми белем бирү программалары (татар һәм рус телләре 1-4 ) Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2010 ел.

2. Даутов Р. Балачак әдипләре. Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2002 ел.

3. Исәнбәт Н., Рәхим Г., Кукушкин Р. Татар балалар поэзиясе антологиясе. Татарстан китап нәшрияты, 1980.

4. Л.И.Минһаҗева, И.Х.Мияссарова. Татар балалар әдәбиятыннан хрестоматия. 1том, Казан ТаРИХ- 2010.

5. Шакирова Т., Шәех Л. Балачак энциклопедиясе. Казан. Татарстан китап нәшрияты, 2010.

6. Ягъфәрова Р.Х. Уку китабы ( 1-2 кисәк). “Мәгариф” нәшрияты, 2010 ел.

***Әдәби уку***
***Календарь - тематик план***

**Сыйныф:** *4*

**Укытучы:** *Калинина Мәкфия Биктимир кызы*

**Беренче яртыеллыкта:** *32 сәг.,* **икенче яртыеллыкта**: *38 сәг.*

**Барысы:** 70 *сәг.*; **атнага:** *2 сәг.*

**Арадаш аттестация:** 1 сәгать

- **Календарь-тематик план** "Башлангыч гомуми белем бирү программалары"на нигезләнеп төзелде.( Авторлары: С.Г.Вагыйзов, Р.Х.Ягъфәрова. *Казан «Мәгариф»,2010)*

**Дәреслек:** *Р.Х.Ягъфәрова. "Уку китабы". 4 нче сыйныф өчен дәреслек. Казан ."Мәгариф". 2009.*

# *Календарь - тематик план*

| *Тәртип саны* | *Дәрес темасы* | *Сәг саны* | *Дәреснең тибы* | *Үзләштерелергә тиешле махсус белем һәм күнекмәләр* | *Контроль төре* | *Дата* | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | *план* | *факт* |
| 1. | **Туган якта җәй һәм көз.** Кереш дәрес.”Татар теле-анам теле”. М.Гафури. Ана теле. | 1 сәг. | Комбиниров | Тиз, аңлап дөрес уку. Эчтәлекне сөйләргә өйрәнү. | агымдагы | 2.09 | 2.09 |
| 2. | И.Гази.Кояш артыннын киткән тургай. | 1 сәг. | Комбиниров | Ашыкмыйча, матур итеп сәнгатьле итеп уку һәм сөйләү. | агымдагы сәнгатьле уку | 7.09 | 7.09 |
| 3. | Р.Миңнуллин Җәйнең яшел аты. | 1 сәг. | Комбиниров | Тиз, аңлап дөрес уку. Эчтәлекне сөйләргә өйрәнү. | агымдагы | 9.09 | 9.09 |
| 4. | Г.Исхакый.Идел буенын көзләрендә. | 1 сәг. | Комбиниров | Ашыкмыйча, матур итеп сәнгатьле итеп уку һәм сөйләү. | агымдагы | 14.09 | 14.09 |
| 5. | Ә.Бикчәнтәева. Көз | 1 сәг. | Яңа матери-алны өйрәнү | Тема белән кызыксынып, уйны ачык итеп әйтергә өйрәнү. | агымдагы | 16.09 | 16.09 |
| 6. | Д.т.у.Туган якта көз.(шагыйрь-ләребезнең көз турындагы шигырьләре) | 1 сәг. | Комбиниров | Укучыны уйлау алымнарына өйрәтү, уйны теләп әйтеп бирергә күнектерү | агымдагы сәнгатьле уку | 21.09 | 21.09 |
| 7. | **Татар халык авыз иҗаты.** Җырлар. | 1 сәг. | Комбиниров | Укучыны мөстәкыйль фикер йөртергә күнектерү. | тематик | 23.09 | 23.09 |
| 8. | Мәкальләр һәм әйтемнәр. | 1 сәг. | Яңа матери-ал ы өйрәнү | Образлар аша укучыларга әхлак тәрбиясе бирү. | тематик | 28.09 | 28.09 |
| 9. | Табышмаклар | 1 сәг. | Комбиниров | Сүзләрнең дөрес әйтелешенә, басымнарның дөрес куелышына, тәэсирле итеп укуга өйрәтү. | тематик эчтәлек сөйләү | 30.09 | 30.09 |
| 10. | “Өч сорау “әкияте | 1 сәг. | Комбиниров | Ашыкмыйча, матур итеп сәнгатьле итеп сөйләү. | агымдагы эчтәлек сөйләү | 5.10 | 5.10 |
| 11. | Гакыллы хәйлә хикәяте. | 1 сәг. | Комбиниров | Шигырь җөмләләрен кыскартыбрак үз сүзебез белән әйтә белү, анализ ясарга өйрәтү. | агымдагы | 7.10 | 7.10 |
| 12. | “Унөч “әкияте. | 1 сәг. | Яңа матери-алны өйрәнү | Ашыкмыйча, матур итеп сәнгатьле итеп сөйләү. | агымдагы сәнгатьле уку | 12.10 | 12.10 |
| 13. | “Каракош” әкияте. | 1 сәг. | Комбиниров | Сыйфатларны барлау, | агымдагы сәнгатьле уку | 14.10 | 14.10 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | гомумиләштерү. | | | |
| 14. | Д.т.у.Татар халык авыз иҗаты. | 1 сәг. | Комбиниров | Образлар аша укучыларга әхлак тәрбиясе бирү. | агымдагы план төзү | 19.10 | 19.10 |
| 15. | **Мәшһүр татар язучылары һәм шагыйрьләре.**<br>Г.Тукай Исемдә калганнар. | 1 сәг. | Комбиниров | Сүзләрнең дөрес әйтелешенә, басымнарның дөрес куелышына, тәэсирле итеп укуга өйрәтү. | тематик эчтәлек сөйләү | 21.10 | 21.10 |
| 16. | Г.Тукай. Китап. | 1 сәг. | Комбиниров | Укучыны мөстәкыйль фикер йөртергә күнектерү. | тематик | 26.10 | 26.10 |
| 17. | Г.Тукай. Туган авыл. “ Шүрәле” поэмасы | 1 сәг. | Комбиниров | Образлар аша укучыларга әхлак тәрбиясе бирү. | агымдагы план төзү | 28.10 | 28.10 |
| 18. | Г.Тукай.Сөткә төшкән тычкан. Арыслан илә Тычкан. Бәхет. | 1 сәг. | Комбиниров | Ашыкмыйча, матур итеп сәнгатьле итеп сөйләү. | агымдагы | 9.11 | 9.11 |
| 19. | Ф.Әмирхан.Ай өстендәге Зөһрә кыз. | 1 сәг. | Контроль | Әсәргә анализ алымын үзләштерү һәм ныгыту. | агымдагы | 11.11 | 11.11 |
| 20. | К.Тинчурин.Очрашу. | 1 сәг. | Яңа матери-алны өйрәнү | Әсәрне өлешләргә таркату, охшашларын җыю, гомимиләштерү | агымдагы | 16.11 | 16.11 |
| 21. | Ш.Камал.Курай тавышы. | 1 сәг. | Комбиниров | Тиз, аңлап дөрес уку. Эчтәлекне сөйләргә өйрәнү. | агымдагы | 18.11 | 18.11 |
| 22. | Г.Ибраһимов.Яз башы. | 1 сәг. | Комбиниров | Ашыкмыйча, матур итеп сәнгатьле итеп сөйләү. | тематик уку тизлеген тикшерү | 23.11 | 23.11 |
| 23. | Һ.Такташ.Кыш җыры. | 1 сәг. | Комбиниров | Тема белән кызыксынып, уйны ачык итеп әйтергә өйрәнү. | агымдагы | 25.11 | 25.11 |
| 24. | Х.Туфан.Һәркемнең үз теле.<br>“ Туган тел” шигыре | 1 сәг. | Комбиниров | Укучыны уйлау алымнарына өйрәтү, уйны теләп әйтеп бирергә күнектерү | агымдагы | 30.11 | 30.11 |
| 25. | Х.Туфан.Сез таныйсызмы?. | 1 сәг. | Комбиниров | Укчыны мөстәкыйль фикер йөртергә күнектерү. | агымдагы | 2.12 | 2.12 |
| 26. | Ш.Маннур.Әткәм-әнкәмнең теле. | 1 сәг. | Комбиниров | Укчыны мөстәкыйль фикер йөртергә күнектерү.<br>Сөйләм телләрен үстерү. | агымдагы | 7.12 | 7.12 |
| 27. | М.Җәлил.Кечкенә дуслар. | 1 сәг. | Комбиниров | Әсәргә анализ алымын үзләштерү һәм ныгыту. | тематик | 9.12 | 9.12 |
| 28. | Д.т.у.М.Җәлил шигырьләре. | 1 сәг. | Контроль | Шигырьне үз сүзебез белән әйтә белү, анализ ясарга өйрәтү. | тематик | 14.12 | 14.12 |
| 29. | И.Гази.Сиртмәкойрык. | 1 сәг. | Яңа матери-алны өйрәнү | Образлар аша укучыларга әхлак тәрбиясе бирү | агымдагы | 16.12 | 16.12 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 30. | Ф.Хөсни.Сөйләнмәгән хикәя. | 1 сәг. | Комбиниров | Сүзләрнең дөрес әйтелешенә басымнарның дөрес куелышына, тәэсирле итеп укуга өйрәтү | агымдагы | 21.12 | 21.12 |
| 31. | А.Гыйләҗев.Дүртәү. | 1 сәг. | Комбиниров | | сәнгатьле уку | 23.12 | 23.12 |
| 32. | С.Хәким.Тукайга. Туган якта һәр тал җырлый. | 1 сәг. | Комбиниров | Сыйфатларны барлау, гомумиләштерү. Әсәргә анализ алымын үзләштерү һәм ныгыту. | сәнгатьле уку | 28.12 | 28.12 |
| 33. | Г.Бәширов. Язгы Сабантуйлар. | 1 сәг. | Яңа матери-алны өйрәнү | Әсәргә анализ алымын үзләштерү һәм ныгыту | сәнгатьле уку | 13.01 | 13.01 |
| 34. | Ә.Еники.Матурлык. | 1 сәг. | Комбиниров | Тиз, аңлап дөрес уку. Эчтәлекне сөйләргә өйрәнү. | агымдагы | 15.01 | 15.01 |
| 35. | Д.т.у.Н.Исәнбәт .Хуҗа Насретдин. “Мыраубай батыр” әкиятеннән өзекләр. | 1 сәг. | Комбиниров | Ашыкмыйча, матур итеп сәнгатьле итеп сөйләү. | агымдагы | 20.01 | 20.01 |
| 36. | М Әмир.Җиргән теле. | 1 сәг. | Комбиниров | Ашыкмыйча, матур итеп сәнгатьле итеп сөйләү. | агымдагы | 22.01 | 22.01 |
| 37. | **Туган якта кыш һәм яз .** Н.Думави.Беренче кар. | 1 сәг. | Комбиниров | Тема белән куызыксынып, уйны ачык итеп әйтергә өйрәнү | агымдагы | 27.01 | 27.01 |
| 38. | Г.Хәсәнов.Декабрь. | 1 сәг. | Комбиниров | Укучыны уйлау алымнарына өйрәтү, уйны теләп әйтеп бирергә кунектерү | тематик | 29.01 | 29.01 |
| 39. | Г.Камал.Масра авылында яз башы. | 1 сәг. | Комбиниров | Образлар аша укучыларга әхлак тәрбиясе бирү | тематик | 3.02 | 3.02 |
| 40. | Г.Ибраһимов.Балыкка бару. | 1 сәг. | Комбиниров | Сүзләрнең дөрес әйтелешенә, басымнарның дөрес куелышына карап тәэсирле итеп укырга өйрәтү. | тематик | 5.02 | 5.02 |
| 41. | Д.т.у.Кыш һәм яз турындагы шигырьләр. | 1 сәг. | Комбиниров | Әсәргә анализ алымын үзләштерү һәм ныгыту. | агымдагы | 10.02 | 10.02 |
| 42. | **Тәрҗемә әсәрләр.** Я.,В.Гримм.Кызыл калфак. | 1 сәг. | Комбиниров | Сыйфатларны барлау, гомумиләштерү. | сәнгатьле уку | 12.02 | 12.02 |
| 43. | Г.Х.Андерсен.Патшаның яңа киеме. | 1 сәг. | Комбиниров | Әсәргә анализ алымын үзләштерү һәм ныгыту. | сәнгатьле уку | 17.02 | 17.02 |
| 44. | А.С.Пушкин.Балыкчы һәм балык турында әкият. | 1 сәг. | Комбиниров | Әсәрне өлешләргә таркату, охшашларын җыю, гомимиләштерү. | сәнгатьле уку | 19.02 | 19.02 |
| 45. | А.С.Пушкин.Балыкчы һәм балык турында әкият. | 1 сәг. | Комбиниров | Тиз, аңлап дөрес уку. Эчтәлекне сөйләргә өйрәнү. | сәнгатьле уку | 24.02 | 24.02 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 46. | Л.Н.Толстой.Балачак. | 1 сәг. | Комбиниров | Ашыкмыйча, матур итеп сәнгатьле итеп сөйләү. | сәнгатьле уку | 26.02 | 26.02 |
| 47. | А.М.Горький.Мин ничек укыдым. | 1 сәг. | Комбиниров | Тема белән куызыксынып, уйны ачык итеп әйтергә өйрәнү | сәнгатьле уку | 3.03 | 3.03 |
| 48. | М.Твен.Том Сойер маҗарала-ры. | 1 сәг. | Комбиниров | Укучыны уйлау алымнарына өйрәтү, уйны теләп әйтеп бирергә күнектерү | сәнгатьле уку | 5.03 | 5.03 |
| 49. | А.С.Экзюпери.Нәни принц. | 1 сәг. | Комбиниров | Тиз, аңлап дөрес уку. Эчтәлекне сөйләргә өйрәнү. | сәнгатьле уку | 10.03 | 10.03 |
| 50. | Д.т.у.Дөнья халыклары әдәбияты. | 1 сәг. | Комбиниров | Ашыкмыйча, матур итеп эзлекле итеп сөйләү. | сөйләм телен үстерү | 12.03 | 12.03 |
| 51. | **Язучылар балаларга.** К.Насыйри.Әбүгалисина | 1 сәг. | Комбиниров | Шигырь җөмләләрне, кыскартыбрак үз сүзебез белән әйтә белү, анализ ясарга өйрәтү | тематик | 17.03 | 17.03 |
| 52. | .А Алиш әкиятләре.” Сертотмас үрдәк”, “ Нечкәбил”, “Чукмар белән Тукмар” | 1 сәг. | Контроль | Укчыны мөстәкыйль фикер йөртергә күнектерү. | тематик | 19.03 | 19.03 |
| 53. | Р.Хафизова.Киек каз юлы. | 1 сәг | Яңа матери-алны өйрәнү | Образлар аша укучыларга әхлак тәрбиясе бирү | агымдагы | 2.04 | 2.04 |
| 54. | Ш.Галиев шигырьләре. | 1 сәг. | Комбиниров | Сүзләрнең дөрес әйтелешенә басымнарның дөоес куелышына тәэсирле итеп укуга өйрәтү | | 7.04 | 7.04 |
| 55. | Ш.Галиев шигырьләре. | 1 сәг. | Комбиниров | Тема белән кызыксынып, уйны ачык итеп әйтергә өйрәнү. | агымдагы | 9.04 | 9.04 |
| 56. | Л.Ихсанова. Җир астында җиде көн. | 1 сәг. | Комбиниров | Сыйфатларны барлау, гомумиләштерү. | агымдагы | 14.04 | 14.04 |
| 57. | Д.т.у Н Фәттах “ Энҗеле үрдәк” драмасы. | 1 сәг. | Комбиниров | Әсәргә анализ алымын үзләштерү һәм ныгыту | агымдагы | 16.04 | 16.04 |
| 58. | Н.Дәүли.Каракай йорт эте. | 1 сәг. | Комбиниров | Әсәрне өлешләргә таркату, охшашларын җыю, гомимиләштерү | агымдагы | 21.04 | 21.04 |
| 59. | М.Юныс.Җиде могҗиза. | 1 сәг. | Комбиниров | Тиз, аңлап дөрес уку Эчтәлекне сөйләргә өйрәнү | агымдагы | 23.04 | 23.04 |
| 60. | Г.Сабитов.Айбаш.. | 1 сәг. | Комбиниров | Ашыкмыйча, матур итеп сәнгатьле итеп сөйләү. | агымдагы | 28.04 | 28.04 |
| 61. | Ф.Яруллин.Туган ягы кирәк кешегә. Тугры дус.” Гайни” | 1 сәг. | Комбиниров | Тема белән кызыксынып, уйны ачык итеп әйтергә өйрәнү. | тематик | 3.05 | 3.05 |
| 62. | Д.т.у.М.Юныс.Безнең өй өянке астында | 1сәг. | Контроль | Образлар аша укучыларга | тематик | 5.05 | 5.05 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | иде. | | | әхлак тәрбиясе бирү. | | | |
| 63. | **Шигърият дәфтәре.**<br>Г.Утыз Имәни.Заманага иярү турында. | 1сәг. | Яңа матери-алны өйрәнү | Сүзләрнең дөрес әйтелешенә басымнарның дөрес куелышына тәэсирле итеп укуга өйрәтү | агымдагы | 10.05 | 10.05 |
| 64. | Дәрдемәнд шигырьләре. “ Кояш нурлары” -хикәясе | 1сәг. | Комбиниров | Рифма, строфа төшенчәләре | агымдагы | 12.05 | 12.05 |
| 65. | Арадаш аттестация: тест | 1сәг. | контроль | | | 17.05 | 17.05 |
| 66. | Н.Думави.Җәйге айлы төн. | 1сәг. | Комбиниров | Сыйфатларны барлау, гомумиләштерү. | тест | 19.05 | 19.05 |
| 67. | Ф.Кәрим.Гармун турында. | 1сәг. | Комбиниров | Чагшыштыру төшенчәсе б-н таныш. | агымдагы | 24.05 | 24.05 |
| 68. | Кабатлау. Табигать турында әсәрләр | 1сәг. | Комбиниров | Метафора, сынландыру төшенчәләре | тематик | 26.05 | }26.05 |
| 69. | Кабатлау. Табигать турында әсәрләр | 1сәг. | Комбиниров | Ашыкмыйча, матур итеп сәнгатьле итеп сөйләү. | тематик | 26.05 | |
| 70. | Кабатлау. Җәйгә биремнәр. | 1 сәг. | дәрес - экскурсия | | иҗади сөйләм төзү | 31.05 | 31.05 |

## ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

1.Башлангыч гомуми белем бирү программалары (татар һәм рус телләре 1-4 ) Казан,
“Мәгариф” нәшрияты, 2010 ел.
2. Даутов Р. Балачак әдипләре. Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2002 ел.
3. Исәнбәт Н., Рәхим Г., Кукушкин Р. Татар балалар поэзиясе антологиясе. Татарстан китап нәшрияты, 1980.
4. Л.И.Минһаҗева, И.Х.Мияссарова. Татар балалар әдәбиятыннан хрестоматия. 1том, Казан ТаРИХ- 2010.
5. Шакирова Т., Шәех Л. Балачак энциклопедиясе. Казан. Татарстан китап нәшрияты, 2010.
6. Ягъфәрова Р.Х. Уку китабы ( 1-2 кисәк). “Мәгариф” нәшрияты, 2010 ел.

7.“Кызыклы грамматика”, С.Г.Вагыйзов, Мәгариф, 2003ел

8. ”Татар теленең аңлатмалы сүзлеге”.Казан:Мәгариф.1998.
9. ”Татар теленең фразеологик әйтелмәләр сүзлеге”.Г.Х.Әхәтов.Казан.Татарстан китап нәшрияты.1982.
10. ”1-4 сыйныфлар өчен изложениелар һәм өйрәтү сочинениеләре җыентыгы”.ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы.Өзлексез педагогик белем бирү институты.Яр Чаллы.2010.